СОВЕТ
НОВОМЕЛЬКЕНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗƏЛƏ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЯНА МЭЛКЭН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423725,Республика Татарстан
Мензелинский район, с.Новый Мелькен,
ул.Школьная, д.17а

423725, Татарстан Республикасы,
Минзэлэ районы, Яна Мэлкэн авылы, Школьная
урамы,17а.

телефон: (85555) 2-37-25. E-mailNmel.Mnz@tatar.ru

Карар

от « 27 » март 2020 ел. № 5

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының
Яңа Мәлкән авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю
Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасының “Җирле референдум турында”гы 23-ЗРТ номерлы Законы, Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Мәлкән авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Мәлкән авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.
2. Әлеге карар рәсми төстә басылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә йөклим.

Авыл җирлеге башлыгы Нәҗметдинов З.И.

ТР Минзәлә муниципаль районы
Яңа Мәлкән авыл җирлеге
Башкарма комитеты
Карарына 1 нче кушымта
Дата 27 март 2020 ел. N 5

ТР Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарга үзара салым акчаларын түләтү Минзәлә районы Яңа Мәлкән авыл Җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан,балачактан инвалидлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуына һәм табыш бирүдә белдерелгән мөнәсәбәтенә бәйсез рәвештә, 31 мартка кадәр срокта башкарыла.

3. Аерым категорияле гражданнар өчен:

- Бөек Ватан сугышы ветераннары;
- Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары,
- 1 һәм 2 төркем инвалидлар;
- балачактан инвалидлар;

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр язуы (уведомление) бланкы Җирлекнең мәгълүмати стендында, Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлегенең menselinsk.tatarstan.ru рәсми сайтында бастыру, шулай ук имза куйдырып тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән гражданнарга җиткерелә.

5. Хәбәр язуында (уведомление) гражданнарның үзара салым акчаларын кертүгә түләү реквизитлары, тулысынча яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү күләме, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш (Кушымта).

6. Гражданнарның үзара салымнан кергән акчалата чаралары Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлегенең лицевой счетына керә.

7. Гражданнардан түләү алу почта (хисап оешмалары) переводларын башкаруга физик затларның йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясауга хокукы булган оешмалар, Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы, https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша акчаларны күчерү юлы белән башкарыла.

8. Касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслаучы булып тора.

9. Билгеләнгән срокта гражданнардан алынмаган үзара салым акчалары законда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

2 нче кушымта

ХӘБӘР ЯЗУЫ (УВЕДОМЛЕНИЕ) N ________________ Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү кертү турында

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис.

______________________________________________

Адрес:

______________________________________________ нигезендә

Сезгә _____________ срокка кадәр ________________________ чараларны гамәлгә

______________________________________ ашыруга бер тапкыр түләү кертергә кирәк.

суммада _____ сум, түбәндәге реквизитлар буенча: ____________________

Түләү алучы банкның БИК

______________________________________________

Сч. N

______________________________________________

Кабул итүче Сч. N

______________________________________________

КПП

______________________________________________

КБК ________________ ОКАТО ___________________

Түләү билгеләнеше

______________________________________________

Җитәкче _________________ ______________________________

М.У. (имза) (тулысынча имза)

------------------------ кисү сызыгы ------------------------

Хәбәр язуы (Уведомление) N __________________

Үзара салым буенча бюджетка бер тапкыр түләү кертү турында

______________________________________________

(муниципаль берәмлек атамасы)

суммада _________________ сум.

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис.

______________________________________________

Адресы:

______________________________________________

Алдым "___" ________________ 20___ ел. ______________________

(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Хәбәр язуы төпсәсе (корешок) тотырыла һәм хәбәр язуы түләүченең шәхсән үзенә тапшырылган очракта, Башкарма комитетта кала.